ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Идел-Кама регионара идарәсе эшчәнлеге турындагы мәгълүмат хакында

Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Идел-Кама регионара идарәсе эшчәнлеге турындагы мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Идел-Кама регионара идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Идел-Кама регионара идарәсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Федераль дәүләт экология контролендә (күзәтчелегендә) булырга тиешле объектларга карата профилактик чаралар үткәрү эшен активлаштырырга.

2.2. Табигатьтән файдалану өлкәсендәге законнарны камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне законнар белән өстәмә җайга салу кирәклеге булганда, тиешле тәкъдимнәр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Файдаланылмый торган һәм файдаланыштан чыгарыла торган каты коммуналь калдыклар полигоннарын рекультивацияләү мәсьәләсен тирәнтен өйрәнергә.

3.2. Чистарту корылмаларына, шул исәптән «Иделне чистарту» федераль проекты кысаларында төзелгәннәренә (реконструкцияләнгәннәренә), хезмәт күрсәтүне тикшереп торуны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәмmәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 29 октябре
№ 445-VII ДС